**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Чалпинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге башкарма комитеты**

Үзәк урам, 39, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592)35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 декабрь 2025 ел. № 68

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 17 мартындагы 9 номерлы “Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш һәм өстәмә кертү турында (18.11.2022 №24 карар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 17 мартындагы 9 номерлы “Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш һәм өстәмә кертү турында (18.11.2022 №24 карар редакциясендә) 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктында түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү таләп ителә "сүзләрен" мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү таләп ителә " сүзләренә алмаштырырга»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4_1 пунктчаны өстәргә:

«4_1) мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары вәкаләтләрен башкару өчен ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә бирелгән очракта, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнарының әлеге белешмәләрне күрсәтмичә мөрәҗәгать итүчегә мондый затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда әлеге затның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә” түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: А.М.Мөхәмәтшин